СОВЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станции
Высокая Гора, Высокогорский район,
Республика Татарстан, 422700

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

Кооперативная ур, 5. Биектау т/ю
станциясе поселогы, Биектау районы,
Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-60, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**15 август, 2024 ел** **№ 434**

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитетының мәгариф бүлеге» муниципаль учреждениесенең хокукый хәлен камилләштерү турында» 2016 елның 28 сентябрендәге 85 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Муниципаль норматив хокукый актларны хокукый мониторинг нәтиҗәләре буенча гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советы

**КАРАР ИТТЕ**:

1. Биектау муниципаль районы Советының “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитеты магариф булеге” муниципаль учреждениесенең хокукый нигезен камилләштерү турында”, 2016 ел, 28 нче сентябрь, 85 номерлы Карары (2018 ел, 14 нче декабрь, 267 номерлы Совет Карары редакциясендә) белан расланган “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитеты магариф бүлеге” муниципаль казна учреждениесе турында Нигезламәгә түбәндәге узгарешләрне көртергә:

3.1. пунктының «-балигъ булган укучыларны аларның ризалыгы һәм балигъ булмаган укучыларны аларның ата-аналары (законлы вәкилләре) ризалыгы белән тиешле дәрәҗәдәге һәм юнәлешле белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган башка учреждениеләргә (белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы учреждение эшчәнлеге туктатылган, тиешле лицензиясе гамәлдән чыккан, аның тиешле белем бирү программасы буенча дәүләт аккредитациясеннән мәхрүм ителгән яисә тиешле белем бирү программасы буенча дәүләт аккредитациясенең гамәлдә булу срогы тәмамланган очракта, шулай ук лицензия гамәлдә булуы туктатылып торганда, дәүләт аккредитациясе гамәлдә булуы тулысынча яисә аерым белем бирү дәрәҗәсенә, әзерлекнең эреләтелгән һөнәр төркемнәренә, белгечлекләргә һәм юнәлешләренә карата туктатылып торган очракта) күчерүне тәэмин итә;» абзацын «-балигъ булган укучыларны аларның ризалыгы һәм балигъ булмаган укучыларны аларның ата-аналары (законлы вәкилләре) ризалыгы белән тиешле дәрәҗәдәге һәм юнәлешле белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган башка учреждениеләргә (белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы учреждение эшчәнлеге туктатылган, тиешле лицензиясе гамәлдән

чыккан, аның тиешле белем бирү программасы буенча дәүләт аккредитациясеннән мәхрүм ителгән, дәүләт аккредитациясе гамәлдә булуы туктатылган очракта, шулай ук лицензия гамәлдә булуы туктатылып торган очракта) күчерүне тәэмин итә;» абзацы белән алмаштырырга.

2. Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары — мәгариф булеге начальнигы Халитов Илсур Әхмәтсафый улын "Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитеты магариф булеге" муниципаль казна учреждениесе турында Нигезламане яна редакциядa дәүләт теркәве узу буенча гариза бирүче буларак чыгуны вәкәләтләргә.

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча игълан итәргә һәм Интернет мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендә Биектау муниципаль районының рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Совет рәисе,
муниципаль район Башлыгы Р.Ф. Хисамөтдинов